ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.03. 2019 г.Мензелинск № 231

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Олимп” балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе” өстәмә белем бирү муниципаль-бюджет учреждениесе исемен үзгәртү һәм учреждение Уставын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.01.2019 елдагы “Өстәмә белем дәүләт учреждениеләренең исемен үзгәртү турында”гы №28 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Олимп” балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе” өстәмә белем бирү муниципаль-бюджет учреждениесе исемен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Олимп” Спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – учреждение) итеп үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Олимп” Спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесе Уставын расларга.

3. Гамәлдәге законда билгеләнгән тәртиптә салым органында кабаттан теркәү өчен учреждение директоры Харисова Чулпан Ришат кызына вәкаләтләр бирергә.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының “Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” МКУ җитәкчесе Ф.Г.Хизбуллинга йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев